

# Sauna

*Sadri Hamid*

*First published in* Ak Yul *'White Road', No. 16, 1969, page 1. Oulu, Finland. The prolific Finland Tatar writer Sadri Hamid (1905–1987) was born in Yangepar, now known as the village of Aktuk(ovo) near Sergach. He lived most of his life in Finland. Transcription from Arabic script Fazile Nasretdin; English translation Sabira Stahlberg.*

"Sauna" – what is a sauna? We do not even need to write about that, because it is in the sauna where one sweats with or without whisking, and as we all very well know – the place where we bathe ourselves. Although we will talk about saunas, our topic here is not town saunas, but we want to write only briefly about the saunas in our home (birth) region.

Those saunas are many thousands of years old, a heritage transmitted and remaining with us from our ancestors. In our area, saunas were not only used for bathing. They were used as hospitals as well. When someone fell ill, or a mother was about to give birth to a baby, the sauna was immediately heated. (Perhaps also now it is so.)

Saunas were not only present in Tatar villages, but in all villages of Russians, Moksha (Mordvinian), and there are – that is to say, there were – saunas in villages of other peoples as well. Even if not all houses in (our home village) Yangepar had a sauna, there was a sauna in every fourth house. In earlier times, many saunas were dug out from the earth. Even in 1918 one could sometimes see dug-out saunas in the earth.

When talking about saunas, Finns boast about them, calling them "Finnish saunas". As if their ancestors were the first to invent the sauna, and it has after that, so they assert, spread among other peoples. Three-four million people of this Finnish tribe have for a long time bathed in saunas, and all other peoples in the world have supposedly lived without a sauna until recently... It is not enough that the Finns boast among themselves, but some years ago, in order to take for themselves all the honour before the whole world, they advertised and spread the information about it as the "Finnish sauna".

The original word for sauna must be *çabına*, 's/he whisks', because in earlier times, when there was no soap, people washed with different things. That is, they cleaned their bodies with soap-like things, which they made themselves. After real soaps appeared in the world, with a wad called *munçala* made from thin strips bundled together of the soft inner bark of linden trees, their soaps foamed. Did they after that reject the word *çabına* and began calling the sauna *munça* instead?

The ancestors of the Finns used to live side by side with Tatars, but then the Finns moved away and settled in the lands where they now live. They brought with them the knowledge from their earlier homeland how to build saunas. The Finns, like the Tatars, at first called it *çabına*. But because with time, Finns could not say the ch-sound anymore, instead of *çabına*, did they have to begin using the word sauna?

"While the horse was being shoed, the frog extended its leg, too" is a proverb left to us by our ancestors. Just like the proverbial frog, the Finns boast about "their own Finnish sauna".

*The body surface becomes dirty, and on top of it also the soul gets dirty;*
*there is no peace for the conscience.*
*Why is there a sauna for the body in this world, but none for the soul?*
Abdulla Tukay

# Munça-Monça

*Sadri Hamid*




“Ak yul” *dip atalgan cıyıntıktan küçerelep yazılgan, No. 16, 1969, bit 1, Oulu, Finlandiyä.*

*Üzeşçän tatar yazuçı, Sadri Hamid (1905-1987) Sergaç şähäre yakınındagı Yañıparda, hazerge vakıtta Aktuk(ovo) iseme belän tanılgan avılda, tugan. Omereneñ zur öleşen Finlandiyädä yäşägän.*

*Tekstnı aräp hareflärennän küçerep yazuçı Fazile Nasretdin.*

“Monça”, munça närsä ikänlegen yazıp torırga tiyeş dä tügel. Çönki ul munçada binek belän çabınu, yäki bineksez tirläp, yuınıp çıga torgan urın ikänen hämmäbez bik yahşı beläbez. Munçadan süz başlanılsa da, mäsälä şähär munçaları hakında tügel, fäkat tugan ilebezdäge munçalardan kıska gına itep yazarga niyät.

Ul munçalar niçämä meñ yıllardan birle äbi-babalarıbızdan bezgä kala kilgän miraslar. Bezneñ yaklarda ul munçalarnı kerep çabınır öçen genä tügel. Hattä hastahanägä dä kullanalar ide. Kemdä bulsa sırhaulasa yäki ber ana bäbäy tudırırga bulsa hazer munça yagalar ide. (Bälki bu zamanda da şulaydır.) Ul munçalar tatar avıllarında gına tügel, böten urıs – mukşı häm başka kavımnarnıñ avıllarında da bar, yani bar ide.

Bezneñ Yañıparda här yortta munça bulmasa da, dürt yort sayın ber munça bar ide. Elek zamanlarda küp munçalar cirgä kazıp eşlängän bulgan, 1918 nçe yıllarda da cirgä kazıp eşlägän munçalar kürengäli ide.

Munça digändän fin halkı şul munçalarnı “fin munçası” diyep maktanıp söylänälär. Ul munçalarnı iñ elek äbi-babaylar “käşef” itkännär dä, imeş soñra başka kavımnarnıñ aralarına cäyelgän dilär. Öç-dört/dürt milyonlık ber kavım küp zamannardan berle munçalarda çabınıp kilgännär dä, böten cir yözeneñ halıkları munçasız yäşägännär imeş. Üzara gına maktanuları citmäde, berniçä yıllar elek üzlärenä şöhrät alır öçen böten cir yözenä “fin saunası” diyep “reklamnar” yasap ilannar tarattılar.

Munçanıñ asıl iseme “çabına” bulsa kiräk. Borıngı zamannarda sabınnar bulmau säbäple üzgä törle äyberlär belän yani üzläre eşlägän sabın kebeklär belän öslären paklagannar, çın sabınnar dönyaga çıkkaç yükä kabıkları yani munçalalar belän sabınnarın kübeklätkännär). Şunnan soñ “çabına” digän isemne taşlap munça diyep äytä başlagannar?

Finnärneñ kadim babaları tatarlar tora torgan yaklardan küçep kitkännär dä, äle yäşi torgan cirlärenä urınnaşkannar, häm munçalar da eşlärgä annan belep kilgännär. Finnär dä tatarlar kebek iñ elek “çabına” diyep äytkännär. Tora-bara finnär “ç” harefen äytä belmägännärennän, çabına digän süzne “sauna” diyep äytergä başlagannar bulırga kiräk?

“At ayagın dagalatkanda baka da seragın tıkkan” digän babaylardan kalgan ber mäkal bar, finnär dä baka kebek “bezneñ sauna” diyep maktanalar.

*Kerlänä öst, östenä ruh, hiç hozur – vicdanga yuk.*
*Ni säbäptän cir yözendä, tängä munça, canga yuk?*
Abdulla Tukay

# Мунча

*Садри Хәмид*

«Ак юл» *дип аталган җыентыктан күчерелеп язылды. Сан 16, 1969, бит 1, Оулу, Финляндия.*




*Үзәшчән татар язучы, Садри Хәмид (1905–1987) Сергач шәһәре якынындагы Яңыпарда, хәзерге вакытта Актук(ово) исеме белән танылган авылда туган. Гомеренең зур өлешен Финляндиядә яшәгән. Текстны гарәп хәрефләреннән күчереп язучы Фазилә Насретдин.*

«Монча» мунча нәрсә икәнлеген язып торырга тиеш тә түгел. Чөнки ул мунчада бинек/минек белән чабыну яки бинексез тирләп, юынып чыга торган урын икәнен һәммәбез бик яхшы беләбез. Мунчадан сүз башланылса да, мәсьәлә шәһәр мунчалары хакында түгел, фәкать туган илебездәге мунчалардан кыска гына итеп язарга ният.

Ул мунчалар ничәмә мең еллардан бирле әби-бабаларыбыздан безгә кала килгән мираслар. Безнең якларда ул мунчаларны кереп чабыныр өчен генә түгел, хәтта хастаханәгә дә кулланалар иде. Кем дә булса сырхауласа яки бер ана бәбәй тудырырга булса, хәзер мунча ягалар иде. (Бәлки бу заманда да шулайдыр.) Ул мунчалар татар авылларында гына түгел, бөтен урыс-мукшы һәм башка кавымнарның авылларында да бар, ягъни бар иде.

Безнең Яңы Парда һәр йортта мунча булмаса да, дүрт йорт саен бер мунча бар иде. Элек заманнарда күп мунчалар җиргә казып эшләнгән булган. 1918 нче елларда да җиргә казып эшләнгән мунчалар күренгәли иде.

Мунча дигәннән фин халкы шул мунчаларны «фин мунчасы» диеп мактанып сөйләнәләр. Ул мунчаларны иң элек әби-бабайлар «кәшеф» иткәннәр дә, имеш соңра башка кавымнарның араларына җәелгән диләр. Өч-дүрт миллионлык бер кавым күп заманнардан бирле мунчаларда чабынып килгәннәр дә, бөтен җир йөзенең халыклары мунчасыз яшәгәннәр имеш. Үзара гына мактанулары җитмәде, берничә еллар елек үзләренә шөһрәт алыр өчен бөтен җир йөзенә «фин саунасы» диеп «рекламнар» ясап игъланнар тараттылар.

Мунчаның асыл исеме «чабына» булса кирәк. Борынгы заманнарда сабыннар булмау сәбәпле үзгә төрле әйберләр белән ягъни үзләре эшләгән сабын кебекләр белән өсләрен пакьләгәннәр. Чын сабыннар дөньяга чыккач, юкә кабыклары, ягъни, мунчалалар белән сабыннарын күбекләткәннәр. Шуннан соң «чабына» дигән исемне ташлап, «мунча» диеп әйтә башлаганнар?

Финнәрнең кадим бабалары татарлар тора торган яклардан күчеп киткәннәр дә, әле яши торган җирләренә урнашканнар, һәм мунчалар да эшләргә аннан белеп килгәннәр. Финнәр дә татарлар кебек иң элек «чабына» диеп әйткәннәр. Тора-бара финнәр «ч» хәрефен әйтә белмәгәннәреннән, чабына дигән сүзне «сауна» диеп әйтергә башлаганнар булырга кирәк?

«Ат аягын дагалатканда бака да сыйрагын тыккан» дигән бабайлардан калган бер мәкаль бар, финнәр дә бака кебек «безнең сауна» диеп мактаналар.

*Керләнә өст, өстенә рух, һич хозур – вөҗданга юк.*
*Ни сәбәптән җир йөзендә, тәнгә мунча, җанга юк.*
Габдулла Тукай